СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» сентябрь 2024 ел № 105

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Бюджет законнарына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге Советының 2019 елның 121 нче номерлы (18.12.2020ел №11, 13.03.2023ел №70 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

статьяның 6 пунктында:

10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «10) алучыларның максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны үтәвен тәэмин итә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре, аларны биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртип;»;

11 нче пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктчада «муниципаль район» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга.;

- түбәндәге эчтәлекле 13.1 пунктча өстәргә: «13.1) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары, капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет акчалары керә (Дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш);»;

статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

алучыларның максатчан билгеләнештәге бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны үтәвен тәэмин итә, шулай ук Россия

Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләре, аларны биргәндә билгеләнгән шартлар, максатлар һәм тәртип.»;
статьяның 9 пунктында:
пунктчада «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.;
пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7) бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итә;»;

- түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктлар өстәргә:

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгели;

9) Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.».

Әлеге карарны Татарстан Республикасының (pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының (baltasi.tatarstan.ru)рәсми сайтында урнаштырырга.
Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Глава Пижмарского сельского поселения
Балтасинского муниципального района
Республики Татарстан — Р.Х.Заляев